**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительного комитета Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**«10» апрель 2020 ел** **№ 119**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 23 ноябрендәге 286 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны кайнар аш белән тәэмин итүне оештыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында "гы карарына үзгәрешләр кертү турында (03.06.2013 №135, 31.12.2013 №331, 02.03.2015 №57, 04.12.2015 №340, 18.11.2016 №337, 11.10.2017 №253, 10.11.2017 №289, 28.11.2018 №334, 01.11.2019 №311 карарлар редакциясендә)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 28 августындагы 724 номерлы «2020 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» карарын, Россия Федерациясе Мәгариф Министрлыгының 2020 елның 17 мартындагы 103 номерлы «Башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын, урта һөнәри белем бирү программаларын һәм электрон укыту һәм дистанцион белем бирү технологияләрен кулланып өстәмә гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыруның вакытлыча тәртибен раслау турында» боерыгын үтәү йөзеннән, 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 37 статьясындагы 1 өлеше, 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында" Федераль законның 34 статьясы нигезендә карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 23 ноябрендәге 286 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны кайнар аш белән тәэмин итүне оештыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында "гы карарына (03.06.2013 №135, 31.12.2013 №331, 02.03.2015 №57, 04.12.2015 №340, 18.11.2016 №337, 11.10.2017 №253, 10.11.2017 №289, 28.11.2018 №334, 01.11.2019 №311 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5.4. пункт өстәргә:

«5.4. Дистанцион уку чорында, Азнакай муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының кайнар ашларын, азык-төлек җыелмалары белән (коры паек) алмаштырырга.»

2. Азнакай муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре директорларына Азнакай муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларына азык-төлек җыелмалары (коры паеклар) формалаштырырга һәм таратырга.

3. Әлеге карар 2020 елның 6 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет - телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.http://aznakayevo.tatar.ru

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары
Д. Р. Гыйләҗевка йөкләргә.

Җитәкче А. Х. Шәмсетдинов